Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
Мичурин авыл җирлеге
Мичурин авылында гражданнар җыены
КАРАРЫ

2021 елның 20 ноябре № 1

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Мичурин авыл җирлегенең Мичурин авылында халык җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2021 елның 20 ноябрендә 2022 елда үзара салым кертүгә Лениногорск муниципаль районы Мичурин авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, тыл хезмәтчәннәре, сугыш хәрәкәтләрендә катнашучылардан тыш, 500 (биш йөз) сум күләмендә акча кертү һәм җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме:

- янгын гидрантлары урнаштыру;

-су насосы бинасын ремонтлау

«ӘЙЕ» «ЮК».

соравы буенча узган гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

Халык җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 187 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны - 96 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучылар бертавыштан «ӘЙЕ» позициясе өчен тавыш бирделәр.

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Мичурин авыл җирлегенең Мичурин авылында гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Мичурин авыл җирлеге составына керүче Мичурин авылында гражданнар җыенын узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. 2022 елда үзара салым кертүгә Лениногорск муниципаль районы Мичурин авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, тыл хезмәтчәннәре, сугыш хәрәкәтләрендә катнашучылардан тыш, 500 (биш йөз) сум күләмендә акча кертү һәм җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме:

- янгын гидрантлары урнаштыру;

-су насосы бинасын ремонтлау

соравы буенча карарны кабул ителгән, дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Мичурин авылы, Совет ур., 26 йорт-административ бина, Совет ур., 28 йорт-мәдәният йорты бинасы; Яңа Сережкино авылы, Үзәк ур., 9 адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында, Лениногорск муниципаль районының рәсми Интернет-сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.r) урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Мичурин авыл җирлеге башлыгы Р.Ә.Иванова